# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 20 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);

2) махсуслаштырылган техниканы карап тоту - «Беларус-82.1 " тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

3) Зур Нөркәй  урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктырту яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);

4) Зур Нөркәйдә төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (үлән чабу);

5) Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча җыю;

6) некрологларны район «Сарман” газетасында бастырып чыгару»;

7) Зур Нөркәй авылында С. Рәфыйков урамында 300 м озынлыктагы вак таш җәю (вак таш ташу) ;

8) Зур Нөркәй т. п. янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Зур Нөркәй авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыеннда рәислек итүче Р.М.Гайсин